| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 11.12.2024 | г.Казань | № 373-18/тэ-2024 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2023 ел, №669-68/тэ-2023 карары белән билгеләнгән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифларны 2025 елга төгәлләштерү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 11.12.2024 ел, №31-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2024 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2025 елга җылылык китерү матдәсенә озак сроклы тарифларны төгәлләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024-2028 елларга кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар билгеләү турында» 14.12.2023 ел, №669-68/тэ-2023 карары белән билгеләнгән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан

бирелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифларны 2025 елга төгәлләштереп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төгәлләштерелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 ел, №669-68/тэ-2023
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2024 № 373-18/тэ-2024
карары редакциясендә)

«Түбән Кама ҖЭҮ» АҖ тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга бирелә торган җылылык китерү матдәсенә 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| №т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | Җылылык чыганагы матдәсе җитештерелә торган җылылык энергиясе чыганагы (чыганаклары) булган җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясе матдәсенә тариф | | | | |
| 1.1 | "Түбән Кама ҖЭҮ" ҖЧҖ | бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 22,10 | - |
| | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 36,02 | - |
| | | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 30,35 | - |
| | | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 30,35 | - |
| | | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 32,21 | - |
| | | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 32,60 | - |
| | | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 32,60 | - |
| | | | 01.07.2027 | 34,43 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | башлап 31.12.2027 кадәр | | |
| | | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 34,43 | - |
| | | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 34,52 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге